**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

18.12.2017 ел № 111

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына җирле үзидарә оештыруны камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 18 апрелендәге 83-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставы нигезләмәләрен федераль законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне, билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан соң, бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар дәүләт теркәве һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Р.М. Нуруллин**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 декабрендәге 111 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Кадер авыл җирлеге Уставына**
**үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пунктны өстәргә:
«15) физик культураны һәм инвалидлар спортын, сәламәт ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларга, адаптив физик культура һәм адаптив спортка ярдәм итү.»;
2. 19 статьяның 3 өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә:
«2.1) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;»;
б) 3 пунктта «муниципаль берәмлекне үстерү планнары һәм программалары проектлары,» сүзләрен төшереп калдырырга;
3. 32 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;»;
4. 47 статьяның 1пунктында:
а) 2 абзацта «җирлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3 абзацта «җирлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнарын һәм программаларын үтәүне оештыра» сүзләрен төшереп калдырырга;
в) 4 абзацта «җирлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнарын һәм программаларын үтәү турында хисап» сүзләрен төшереп калдырырга;
г) түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:
«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;»;
5. 47 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-физик культураны һәм инвалидлар спортын, сәламәт ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларга, адаптив физик культура һәм адаптив спортка ярдәм итә.»;
3. 69 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.».
4. 86 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Әлеге Уставка кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (муниципаль берәмлек уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының вәкаләтләре, вәкаләтләре чоры, сайланулы вазыйфаи затларын сайлау

тәртибе үзгәрүдән тыш) күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне әлеге Уставка кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән җирлек Советының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.».